КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 13 ноябрь г.Казань № 995

Спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү бирүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү бирүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына 30 көн эчендә спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче дәүләт һәм муниципаль оешмаларда эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү бирү тәртибен эшләргә һәм расларга.

3. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип санарга:

«Хезмәт өчен түләүнең яңа системасына күчүгә бәйле рәвештә, балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләрендә эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2010 ел, 28 декабрь, 1133 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Хезмәт өчен түләүнең яңа системасына күчүгә бәйле рәвештә, балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче дәүләт һәм муниципаль мәгариф учреждениеләрендә эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен дәүләт ярдәме күрсәтү чаралары турында» 2010 ел, 28 декабрь, 1133 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2011 ел, 4 март, 174 нче.

5. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2018 ел, 13 ноябрь, 995 нче
карары белән расланды

Спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү бирүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү
ТӘРТИБЕ

1. Бу Тәртип спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү бирүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба – субсидияләр) бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә физик культура һәм массакүләм спортны үстерү өчен шартлар тәэмин итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында, спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү бирү өлешендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына бирелә.

3. Бу Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчасы белән баш эш итүче булып Татарстан Республикасының Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора.

4. Субсидияләр бу Тәртипнең 2 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен тиешле финанс елына Министрлыкка ирештерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

5. Субсидия алу өчен Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрен сайлап алу критерийлары:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегендә балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмалар булу;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары нигезендә үткән календарь ел өчен балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмалар укучыларының бөтенроссия һәм халыкара ярышларда алган югары нәтиҗәләре булу;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары нигезендә үткән календарь ел өчен

балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмалар спортчылар-инструкторларның һәм спортчыларның бөтенроссия һәм халыкара ярышларда алган югары нәтиҗәләре булу.

6. Субсидияләр түбәндәге шартларда бирелә:

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең норматив хокукый акты белән расланган спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү бирүне гамәлгә ашыру тәртибен үз эченә алган спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәсе булу;

Финанслашу өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирелә торган спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләүгә исәпләнгән хезмәт өчен түләү буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә бюджет ассигнованиеләре Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетында бирелә торган субсидия суммасыннан кимендә 50 процент күләмендә булу;

Министрлык белән бу Тәртипнең 9 нчы пункты нигезендә субсидия бирү турында килешү төзү.

7. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары бу Тәртипкә теркәлгән кушымтадагы форма буенча субсидия бирү турында гариза (алга таба – гариза) һәм ярышлар беркетмәсенең расланган күчермәсен Министрлыкка кертә.

8. Субсидия күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = \sum^{n}_{j=1}((O_v \text{ x } Ч_т) + (B_{vrr} \text{x } Ч_с)) \times C \times 12,$$

монда,

$S_i$ – балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү бирүгә i-муниципаль берәмлегенә субсидия күләме;

$O_v$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә таянып исәпләнә торган физик культура һәм спорт өлкәсендә белем бирү программаларын тормышка ашыручы j-муниципаль өстәмә белем бирү оешмасында тренерлар-укытучыларның (өлкән тренерлар-укытучыларның) яулаган урынына карап оклады;

$Ч_т$ – балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче j-муниципаль оешмада югары квалификацияле спортчылар әзерләүне гамәлгә ашыручы тренерлар-укытучылар (өлкән тренерлар-укытучылар) саны;

$B_{vrr}$ – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт белем бирү оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 ел, 31 май, 412 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы өстәмә белем бирүче мәгариф оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турындагы нигезләмәгә таянып исәпләнә торган балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче j-муниципаль оешмада рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында уңышлы чыгышлар һәм ирешелгән нәтиҗәләр өчен спортчыларга һәм, ярышларда яулаган урынга карап, югары эш нәтиҗәләре өчен спортчы-инструкторларга түләүләр;

$Ч_c$ – балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче j-муниципаль оешмада рәсми халыкара, бөтенроссия, округ һәм республика ярышларында уңышлы чыгышлары һәм ирешелгән нәтиҗәләре булган спортчылар һәм ярышларда урыннар алучы спортчы-инструкторлар саны;

С – балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү чыгымнарыннан һәм хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр ставкасыннан чыгып, исәпләп чыгарылган хезмәт өчен түләү буенча түләүләргә исәпләүләр чыгымнары;

n – i-муниципаль оешмада балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмалар саны.

9. Субсидия Министрлык һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге арасында тиешле финанс елының 25 гыйнварыннан да соңга калмыйча төзелә торган субсидия бирү турындагы килешү (алга таба – килешү) нигезендә бирелә, анда түбәндәгеләр күздә тотыла:

субсидиянең максатчан билгеләнеше;

бирелә торган субсидия күләме;

субсидияне күчерү вакытлары;

субсидияне файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләре;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге тарафыннан субсидияне максатчан файдалануны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру;

субсидия алучының финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган чыгымнарны гамәлгә ашыру һәм субсидияне файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турындагы хисапны кертү тәртибе, формасы һәм вакытлары;

бу Тәртип белән билгеләнгән шартлар бозылган очракта, килешүне өзү тәртибе;

яклар җаваплылыгы.

10. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче һәм югары квалификацияле спортчылар әзерләүне гамәлгә ашыручы тренерлар-укытучылар, шулай ук ярышларда алынган нәтиҗәләре булган спортчы-инструкторлар һәм спортчылар реестрын алып бара һәм ай саен, агымдагы айның 5 еннән да соңга калмыйча, субсидия бирүгә гаризаны һәм реестрны Министрлыкка кертә.

11. Министрлык балаларга спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче һәм югары квалификацияле спортчылар әзерләүне гамәлгә ашыручы тренерлар-укытучыларның, шулай ук ярышларда алынган

нәтиҗәләре булган спортчы-инструкторлар һәм спортчыларның җыелма реестрын алып бара һәм ай саен, агымдагы айның 15 еннән да соңга калмыйча, субсидия бирүгә гаризаны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына кертә.

12. Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы Министрлыкның спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү бирүгә гаризасы кергәннән соң, биш эш көненнән дә соңга калмыйча, финанслауның иң чик күләмнәрен әлеге максатларга ирештерү өчен чыгым расписаниесен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының Казначылык департаментына кертә.

13. Министрлык, әлеге максатлар өчен финанслауның иң чик күләмнәре ирештерелгән көннән биш эш көненнән дә соңга калмыйча, субсидияне Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджеты акчасын исәпкә алу өчен Россия Банкының исәп-хисап челтәре бүлекчәләрендә ачылган Федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең исәп-хисап счетына күчерә.

14. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 15 еннән дә соңга калмыйча, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары чыгымнары һәм субсидияне файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турындагы хисапларны килешү белән күздә тотылган форма һәм тәртип нигезендә Министрлыкка кертә.

15. Министрлык ай саен, хисап аеннан соң килүче айның 20 сеннән дә соңга калмыйча, финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары чыгымнары һәм субсидияне файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен үтәү турындагы хисапны Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы белән билгеләнгән форма нигезендә Татарстан Республикасының Финанс министрлыгына кертә.

16. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары законнар нигезендә кертелә торган хисап мәгълүматлары дөрес булмау һәм субсидияләрне максатчан файдаланмау өчен җавап бирә.

17. Субсидияләрне максатчан файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

18. Субсидияне максатчан файдаланмау Татарстан Республикасы бюджетыннан алынган акча суммасын законнар белән билгеләнгән тәртиптә бәхәссез түләттерүгә китерә.

19. Агымдагы финанс елының 1 гыйнвары хәленә карата файдаланылмаган субсидияләр агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемен кире кайтарылырга тиеш.

Субсидияләрнең файдаланылмый калган өлеше Татарстан Республикасы бюджеты керемен күчерелмәгән очракта, әлеге акча, Россия Федерациясенең Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы бюджеты керемен Татарстан Республикасының Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә түләттерелергә тиеш.

___

Спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү бирүгә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә
кушымта

Форма

Спорт юнәлешендә өстәмә белем бирүче муниципаль оешмаларда эшләүче тренерлар-укытучыларга югары квалификацияле спортчылар әзерләгән өчен, шулай ук спортчы-инструкторларга һәм спортчыларга ярышларда алынган нәтиҗәләр өчен түләү бирүгә ___________________ муниципаль районы (шәһәр округы) бюджетына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр алуга
гариза

| Т/с | Муниципаль район (шәһәр округы) исеме | Учреждение исеме | Спортчы-инструкторның фамилиясе, исеме, атасының исеме | Спорт төре | Нәтиҗә күрсәткән спортчының фамилиясе, исеме, атасының исеме | Спортчының нәтиҗәсе (алынган урын) | Ярыш рангы | Тренер-укытучының база оклады | Нәтиҗә өчен % | Ставкаларны исәпкә алмыйча, 1 айга түләү суммасы, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

_______________________________